ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13 июня 2017 ел № 3576

«2017-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре халкының гомер озынлыгын һәм тормыш сыйфатын арттыру» муниципаль программасы турында

Шәһәрнең тотрыклы социаль-икътисадый һәм рухи үсешен тәэмин итү өчен уңай социаль мохит булдыру, гражданнарның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, социаль тотрыклылыкны саклау, алкогольле продукцияне чамадан тыш куллану күренешләренә карата, шул исәптән яшүсмерләр һәм яшьләр арасында, җәмгыятьнең түземсезлеген формалаштыру, Яр Чаллы шәһәре халкының төрле катлауларын сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләрен формалаштыруга юнәлдерелгән даими физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 41, 53 статьялары, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2013 елның 11 декабрендәге 7511 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «2017-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре халкының гомер озынлыгын һәм тормыш сыйфатын арттыру» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2017 елның 13 июнендәге
3576 номерлы карарына
кушымта

«2017-2020 елларга
Яр Чаллы шәһәре халкының
гомер озынлыгын һәм тормыш сыйфатын арттыру»
муниципаль программасы

# 1 бүлек. «2017-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре халкының гомер озынлыгын һәм тормыш сыйфатын арттыру» муниципаль программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2017-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре халкының гомер озынлыгын һәм тормыш сыйфатын арттыру» муниципаль программасы (алга таба – программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Халыкның санитар–эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон; «Гражданнарның сәламәтлеген әйләнә-тирә тәмәке төтене йогынтысыннан һәм тәмәке куллану нәтиҗәләреннән саклау турында» 2013 елның 23 февралендәге 15-ФЗ номерлы Федераль закон; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 30 декабрендәге 2128-р номерлы Боерыгы белән расланган 2020 елга кадәр халык арасында алкоголь продукциясен чамадан тыш куллану масштабларын киметү һәм алкоголизмны профилактикалау буенча дәүләт сәясәтен тормышка ашыру концепциясе; «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында алкогольле продукцияне, сыраны, тәмәкене чамадан тыш куллануны киметү һәм халык арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча өстәмә чаралар турында» 2010 елның 29 октябрендәге 867 номерлы Карары; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы Карары; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 17 июнендәге 443 номерлы Карары белән расланган 2015-2025 елларга Татарстан Республикасында укучыларны тәрбияләүне үстерү стратегиясе |
| Программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе |
| Программаны башкаручылар | Башкарма комитетның Автозавод, Үзәк, Комсомол районнары хакимиятләре, Башкарма комитетның мәгариф |

| | |
|---|---|
| | идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе, Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе |
| Программаның максаты | Яр Чаллы шәһәре халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, алкогольле продукцияне чамадан тыш куллану масштабларын киметүгә юнәлдерелгән комплекслы чаралар системасын булдыру һәм алкоголизм һәм тәмәке тартуны профилактикалау |
| Программаның бурычлары | 1. Алкогольле, спиртлы һәм тәмәке продукциясен законсыз сатуга каршы тору буенча эшне активлаштыру.<br>2. Шәһәрнең тотрыклы социаль-икътисадый һәм рухи үсешен тәэмин итү өчен уңай социаль мохит булдыру, гражданнарның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, социаль тотрыклылыкны саклау.<br>3. Алкогольле продукцияне чамадан тыш куллану күренешләренә карата, шул исәптән яшүсмерләр һәм яшьләр арасында, җәмгыятьнең түземсезлеген формалаштыру.<br>4. Алкогольле продукцияне чамадан тыш кулланучыларга, алкоголизм белән авыручыларга наркологик медицина ярдәме күрсәтүне оештыруны камилләштерү.<br>5. Халыкның төрле катлауларын сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләрен формалаштыруга юнәлдерелгән даими физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү. |
| Программаны тормышка ашыру сроклары | 2017-2020 еллар |
| Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Программаны тормышка ашыруга акча бүлеп бирү каралмаган |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә 2020 елда түбәндәгеләр күздә тотыла:<br>1) алкогольле һәм тәмәке продукциясен ваклап сату өлкәсендә хокук бозулар санын киметергә;<br>2) «алкоголь белән көчле агулану» диагнозлы балигъ булмаганнарның чагыштырма авырлыгын киметергә;<br>3) эшкә урнаштырылган «куркыныч төркем» гражданнары санын арттырырга;<br>4) һөнәри ориентация хезмәтеннән файдаланган гражданнар санын арттырырга; |

| | |
|---|---|
| | 5) социаль адаптация хезмәтеннән файдаланган гражданнар санын арттырырга;<br>6) «Без сәламәт яшәү рәвеше өчен» акцияләрендә катнашучылар санын арттырырга;<br>7) халык арасында тискәре күренешләрне бетерү буенча массакүләм мәгълүмат чараларында (радио, телевидение, матбугат, Интернет) урнаштырылган мәгълүмати материаллар санын арттырырга;<br>8) балигъ булмаганнар арасында исерек хәлдә кылынган җинаятьләр санын киметергә;<br>9) алкогольгә бәйлелеге булган һәм реабилитация узган авыруларның чагыштырма санын арттырырга;<br>10) сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга юнәлдерелгән массакүләм акцияләр санын арттырырга;<br>11) гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми санында «Спорт – начар гадәтләргә альтернатива» акциясендә катнашучы укучылар өлешен арттырырга. |
| Программаның тормышка ашырылуын контрольдә тотуны оештыру системасы | Программа үтәлешенә гомуми контрольне Башкарма комитет гамәлгә ашыра |

2 бүлек. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа методы белән хәл итү кирәклеген нигезләү

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 30 декабрендәге 2128-р номерлы Боерыгы белән расланган 2020 елга кадәр халык арасында алкоголь продукциясен чамадан тыш куллану масштабларын киметү һәм алкоголизмны профилактикалау буенча дәүләт сәясәтен тормышка ашыру концепциясе нигезендә, алкогольле продукцияне чамадан тыш куллану Россиядә тиз арада демографик һәм социаль проблемалар җыелуга төп сәбәп булды. Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 31 декабрендәге 683 номерлы Указы белән расланган Россия Федерациясенең Милли иминлек стратегиясе нигезендә, халык санын тотрыкландыру һәм демографик хәлне тамырдан яхшырту милли иминлекне тәэмин итүнең стратегик максатлары булып тора, ә алкоголизм сәламәтлек саклау өлкәсендә милли иминлекнең төп куркынычларыннан берсе дип аталды.

Яр Чаллы шәһәрендә демографик хәл, тулаем алганда, тотрыклы саклана, 2016 ел нәтиҗәләре буенча туучылар саны 1000 кешегә 15,7 % тәшкил итә. 2013 елда – 15,6 %, 2014 елда – 15,3 %, 2015 елда – 15,7 %.

2016 елда табигый үсеш 7,4 %, 2015 елда +7,1 %, 2014 елда + 6,7 %, 2013 елда +7,5 % тәшкил итте.

2016 елда барлык халык арасында беренчел авырулар саны 4,8% ка кимегән. Татарстан Республикасында соңгы 5 елда беренчел авырулар санының 5% ка кимүе күзәтелә.

Яр Чаллы шәһәренең барлык халкы арасында авыруларның таралуы арта, 2016 әлеге күрсәткеч 1738,7 кешегә җитте, 2013 ел белән чагыштырганда 1,5 % ка киму күзәтелә. 5 ел белән чагыштырганда шәһәр һәм Татарстан Республикасы буенча авырулар таралуның кимүе 1,8% тәшкил итте.

Аерым социаль-әһәмиятле төркемнәр буенча авырулар йөз мең кешегә түбәндәгечә тәшкил итте:

- 2016 елда яман шеш авырулары -378,6 кеше, 2013 ел белән чагыштырганда 10% ка үсеш күзәтелә. Соңгы 5 елда 19% ка;
- 2016 елда туберкулез – 32,3 кеше, 5 ел эчендә 15% ка кимегән;
- 2016 елда наркология авырулары (шул исәптән профилактик күзәтү) – 111,3 кеше, 5 ел эчендә таралуның гомуми күләме 45,7% ка кимүе билгеләнә.

Татарстан Республикасында министрлыклар, ведомстволар, дәүләт комитетлары, муниципаль берәмлекләр, иҗтимагый оешмалар алкогольле продукцияне чамадан тыш куллануны профилактикалау, халык арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча максатчан комплекслы эш алып баралар.

Яр Чаллы шәһәрендә законнарның билгеләнгән таләпләренең үтәлешен контрольдә тоту тәэмин ителә, алкогольле продукцияне чамадан тыш куллануның зыяны турында белемнәрне популярлаштыру даими рәвештә тормышка ашырыла, сәламәт яшәү рәвешен алып баруга мотивация формалаштыруга ярдәм итә торган шартлар тудырыла. Белем бирү оешмаларында «Мәгариф һәм сәламәтлек», «Мәктәп - сәламәтлек территориясе», «Лидерлык нигезләре», «Мөстәкыйль балалар», «профилактиканың мәктәп отрядлары» комплекслы проектлары тормышка ашырыла.

Чаралар күрү нәтиҗәсендә исерек хәлдә кылынган җинаятьләр саны кими, алкоголизм белән авыручылар саны кими, ә алкоголизмнан дәвалanучылар һәм реабилитация узучылар саны арта бара.

Шул ук вакытта шәһәр халкын алкоголь белән тәэмин итү проблемасының актуальлеге саклана. Моңа түбәндәге факторлар йогынты ясый:

- тиешле лицензиядән башка гына алкогольле продукцияне ваклап сатучы затлар санының артуы;
- шәһәр территориясенә легаль булмаган алкогольле продукцияне законсыз кертү, шулай ук халыкка «икеләтә» билгеләнештәге спиртлы продукция сатучы билгеле бер затларның законсыз эшчәнлеге дәвам итү;
- халыкта алкогольле продукцияне чамадан тыш кулланган кешеләргә, шул исәптән яшьләр арасында да, түземле мөнәсәбәт булу;
- балалар, яшүсмерләр һәм яшьләрнең ялын оештыруның җитәрлек дәрәҗәдә нәтиҗәле һәм сыйфатлы булмавы.

Алкогольле продукцияне чамадан тыш куллану, булдырмый калу мөмкин булган сәбәпләр нәтиҗәсендә кешеләрнең вакытыннан алда үлеменә китерә һәм җәмгыятьнең билгеле бер өлешендәге социаль деградациянең төп сәбәпләренең берсе булып тора, ул җинаятьчелек, көчләү, ятимлек, сәламәтлек начараю, инвалидлык һәм суицид очракларының артуына китерә.

Ел саен исерек хәлдә күп санлы җинаятьләр кылына – үтерү, сәламәтлеккә авыр зыян китерү, көчләү, хулиганлык, урлау, талау, автотранспорт урлау.

2016 елда Яр Чаллы шәһәре буенча алкоголь белән агуланучы 16 кеше теркәлгән, шул исәптән 1 пенсионер һәм 15 эшкә яраклы кеше. «Яр Чаллы шәһәре халкын эш белән тәэмин итү үзәг» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – мәшгульлек үзәге) тарафыннан гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә ярдәм итү буенча эш алып барылган. Бүгенге көндә алкоголь белән агуланучы барлык гражданнарның 4 се эшли, 3 кеше мәшгульлек үзәге хезмәтләреннән баш тарткан. 2 кеше мәшгульлек үзәгенә чакырылган, әмма мөрәҗәгать итмәгән. «Хәвеф төркеме» ндәге эшләмәүче һәр граждан белән максатчан эшләргә кирәк.

Алкогольле продукцияне күп кенә яшүсмерләр дә куллана. 2016 елда Яр Чаллы шәһәрендә яшүсмерләр арасында алкоголь белән көчле агулануның 34 очрагы теркәлгән, 2015 елда – 22 очрак.

Балаларны һәм яшьләрне яшьтән үк алкогольле продукциягә җәлеп итү киләчәктә алкоголизм һәм үтерелү куркынычын берничә тапкыр арттыра.

Алкогольле продукцияне чамадан тыш куллану 40-60 яшьлек ир-атлар арасында үлемнең аеруча югары дәрәҗәсен тудыра, бу яшьтә алар иң кыйммәтле һөнәри күнекмәләргә ия. Аларның вакытыннан алда китүе һөнәри тәҗрибәгә ия булган хезмәт ресурсларына зыян китерә, кеше капиталына инвестицияләр күләмен киметә.

Кызганычка каршы, халыкның күпчелеге өчен сәламәтлек әхлакый кыйммәт тә, икътисадый кыйммәт тә булып тормый. Алкоголь һәм тәмәке куллану дәрәҗәсе югары булып кала бирә. Алкоголь һәм аның суррогатлары белән үлемгә китергән агуланулар, агулануның үлемгә китергән барлык очракларының өчтән бер өлешен тәшкил итә.

Халык сәламәтлеген саклау медицина бурычы гына түгел. Аны төрле ведомстволар, иҗтимагый оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәттәшлеге нигезендә тормышка ашырырга мөмкин.

## 3 бүлек. Программаның төп максатлары һәм бурычлары

Программаны тормышка ашыру 5 елга – 2017-2020 елларга исәпләнгән.

Программаның максаты: Яр Чаллы шәһәре халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, алкогольле продукцияне чамадан тыш куллану масштабларын киметүгә юнәлдерелгән комплекслы чаралар системасын булдыру, шулай ук алкоголизм һәм тәмәке тартуны профилактикалау.

Программаның бурычлары:

- алкогольле һәм тәмәке продукциясен законсыз сатуга каршы тору буенча эшне активлаштыру;

- шәһәрнең тотрыклы социаль-икътисадый һәм рухи үсешен тәэмин итү өчен уңай социаль мохит булдыру, гражданнарның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, социаль тотрыклылыкны саклау.

- алкогольле продукцияне чамадан тыш куллану күренешләренә карата, шул исәптән яшүсмерләр һәм яшьләр арасында, җәмгыятьнең түземсезлеген формалаштыру.

- алкогольле продукцияне чамадан тыш кулланучыларга һәм алкоголизм белән авыручыларга наркологик ярдәм күрсәтүне оештыруда ярдәм күрсәтү;

- халыкның төрле катлауларын сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләрен формалаштыруга юнәлдерелгән даими физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү.

## 4 бүлек. Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген билгеләргә мөмкинлек бирә торган индикаторлар

Программа чараларының нәтиҗәлелеген бәяләү өчен түбәндәге күрсәткечләрдән файдаланырга тәкъдим ителә:

| № т/б | Индикаторның исеме | Исәпләү методикасы | Чыганак |
|---|---|---|---|
| 1. | Лицензиясе булган сәүдә объектларының гомуми санында лицензиясез эшчәнлек ачыкланган сәүдә объектларының өлеше, процент | Тв = Тл/Тбл x 100, монда<br>Тв – лицензиясез эшчәнлек ачыкланган сәүдә объектларының чагыштырма авырлыгы;<br>Тл – лицензиясе булган сәүдә объектларының саны;<br>Тбл – лицензиясе булмаган сәүдә объектларының саны | Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Яр Чаллы территориаль органы, Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе мәгълүматы |
| 2. | Законсыз эшмәкәрлеккә каршы тору буенча ведомствоара комиссиянең үткәрелгән утырышлары саны | N - сан | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенең хисабы |
| 3. | «Алкоголь белән көчле агулану» диагнозлы балигъ булмаганнарның чагыштырма саны, процент | НА =О/КН x 100, монда<br>НА – алкоголь белән көчле агуланган балигъ булмаганнарның | ТР Россия кулланучылар күзәтчелегенең Яр Чаллы шәһәрендәге, Актаныш районындагы идарәсенең статистика мәгълүматлары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | чагыштырма авырлыгы;<br>О – алкоголь белән көчле агуланган балигъ булмаганнар саны;<br>КН – балигъ булмаганнарның гомуми саны | |
| 4. | Эшкә урнаштырылган өлкән буын гражданнары саны, берәмлек | N – сан | Эш белән тәэмин итү үзәгенең статистика мәгълүматлары |
| 5. | Һөнәри ориентация хезмәтеннән файдаланган гражданнар саны, берәмлек | N – сан | Эш белән тәэмин итү үзәгенең статистика мәгълүматлары |
| 6. | Социаль адаптация хезмәтеннән файдаланган гражданнар саны, берәмлек | N – сан | Эш белән тәэмин итү үзәгенең статистика мәгълүматлары |
| 7. | «Яшьләр сәламәт яшәү рәвеше өчен» акциясендә катнашучылар саны, берәмлек | N – сан | Акцияне оештыручылар: Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе хисабы |
| 8. | Массакүләм мәгълүмат чараларында (радио, телевидение, матбугат, Интернет) урнаштырылган мәгълүмати материаллар саны, берәмлек | N – сан | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | министрлыгының социаль яклау идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе хисабы |
| 9. | Балигъ булмаганнар арасында исерек хәлдә кылынган җинаятьләр саны | N – сан | Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ Идарәсенең балигъ булмаганнар белән эшләү бүлегенең статистик хисабы |
| 10. | Алкогольгә бәйлелеге булган һәм реабилитация узган авыруларның чагыштырма авырлыгы, процент | ДАР = АР / АС х100, монда<br>ДАР – алкогольгә бәйлелеге булган һәм реабилитация узган авыруларның өлеше;<br>АР – алкогольгә бәйлелеге булган һәм реабилитация узган авыруларның саны;<br>АС - алкогольгә бәйлелеге булган, стационарда дәваланган һәм реабилитация узмаган авырулар саны | ТР «Яр Чаллы наркология диспансеры» ССМ РНД ДАССУ филиалының статистик хисабы |
| 11. | Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга юнәлдерелгән массакүләм акцияләр саны | N – сан | Акцияне үткәрү йомгаклары буенча профилактика субъектлары хисабы |
| 12. | Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми санында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга юнәлдерелгән акцияләрдә катнашучы укучыларның өлеше, процент | ДОА = УА / ОО х 100, монда<br>ДАО – акциядә катнашучы укучылар өлеше;<br>УА – акциядә катнашучылар саны;<br>ОО – белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми саны | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе хисабы |

## 5 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны тормышка ашыруга акча бүлеп бирү каралмаган.

## 6 бүлек. Программаны тормышка ашыру нтиҗәлелеген бәяләү

Программаны тормышка ашырудан социаль-икътисадый нәтиҗәлелек түбәндәгеләр хисабына ирешеләчәк:

- Яр Чаллы шәһәре халкы арасында алкогольле продукция белән көчле агулануга бәйле үлем дәрәҗәсен киметү;
- исерек хәлдә кылынган җинаятьләр санын киметү;
- балигъ булмаганнар арасында алкоголь белән көчле агуланулар санын киметү;
- халык, шул исәптән яшүсмерләр һәм яшьләр арасында, сәламәт яшәү рәвешен алып баруга мотивация формалаштыру, алкогольле һәм тәмәке продукциясен кулланудан баш тарту.

# 7 бүлек. Программа чаралары

«2017-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре халкының гомер озынлыгын һәм тормыш сыйфатын арттыру» муниципаль программасының максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм чаралары буенча финанслау

| Төп чараның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү срок | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикаторларның зурлыгы | | | | | Финанслау (мең сум) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2016 ел (база) | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| Максат: Яр Чаллы шәһәре халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, алкогольле продукцияне чамадан тыш куллану масштабларын киметүгә юнәлдерелгән комплекслы чаралар системасын булдыру һәм алкоголизм һәм тәмәке тартуны профилактикалау | | | | | | | | | | | | |
| 1 бурыч. Алкогольле һәм тәмәке продукциясен законсыз сатуга каршы тору буенча эшне активлаштыру | | | | | | | | | | | | |
| Тиешле лицензиясе булмаган алкогольле продукцияне ваклап сатуны ачыклау һәм туктату мониторингы | Башкарма комитетның Автозавод, Үзәк, Комсомол районнары хакимиятләре (алга таба - БК районнар хакимиятләре), Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе (алга таба - БК ИҮ һ ЭЯКИ) | 2017-2020 еллар | Лицензиясе булган сәүдә объектларының гомуми санында лицензиясез эшчәнлек ачыкланган сәүдә объектларының өлеше, процент | 6 | 6 | 5 | 5 | 5 | Чара оештыру характерына ия | | | |
| Алкогольле һәм тәмәке продукциясен ваклап сатуга куела торган мәҗбүри таләпләрне үтәү мониторингы | Башкарма комитетның район хакимиятләре, УЭР и П ИК | 2017-2020 еллар | Алкогольле һәм тәмәке продукциясен ваклап сату өлкәсендә закон бозуларның чагыштырма саны | 4 | 3 | 2 | 2 | 2 | Чара оештыру характерына ия | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | (нәтиҗәлелек), процент | | | | | | |
| 2 бурыч. Шәһәрнең тотрыклы социаль-икътисадый һәм рухи үсешен тәэмин итү өчен уңай социаль мохит булдыру, гражданнарның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, социаль тотрыклылыкны саклау | | | | | | | | | |
| «Куркыныч төркем» балаларын һәм яшьләрен өстәмә белем алуга җәлеп итү буенча эшне камилләштерү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе (алга таба – БК МИ), Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе (алга таба – БК ЯЭИ), Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе (алга таба – БК Ф h СИ), Башкарма комитетның мәдәният идарәсе (алга таба – БК МИ) | 2017-2020 еллар | «Алкоголь белән көчле агулану» диагнозлы балигъ булмаганнарның чагыштырма саны, процент | 34 | 30 | 15 | 10 | 5 | Чара оештыру характерына ия |
| «Куркыныч төркем» гражданнарын эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү | БК районнар хакимиятләре | 2017-2020 еллар | Эшкә урнаштырылган өлкән буын гражданнарының саны, берәмлек | 183 | 360 | 360 | 360 | 360 | Чара оештыру характерына ия |
| Эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлап алу максатларында, гражданнарга, шул исәптән белем бирү оешмаларында укучыларга һәм мәшгуль булмаган инвалидларга һөнәри ориентация буенча ярдәм күрсәтү | БК районнар хакимиятләре УО и ДМ ИК | 2017-2020 еллар | Һөнәри ориентация буенча хезмәт күрсәтелгән гражданнарның саны, берәмлек | 8880 | 8880 | 8880 | 8880 | 8880 | Чара оештыру характерына ия |
| Эшсез гражданнарны һәм мәшгуль булмаган инвалидларны хезмәт базарында социаль | БК районнар хакимиятләре | 2017-2020 еллар | Социаль адаптацияләү буенча хезмәт күрсәтелгән | 975 | 867 | 867 | 867 | 867 | Чара оештыру характерына ия |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| адаптацияләүгә ярдәм күрсәтү (эшсезләр саны ел саен кимүне исәпкә алып) | | | гражданнарның саны, берәмлек | | | | | | |
| 3 бурыч. Алкогольле продукцияне чамадан тыш куллану күренешләренә карата, шул исәптән яшүсмерләр һәм яшьләр арасында, җәмгыятьнең түземсезлеген формалаштыру | | | | | | | | | |
| Тематик пресс-конференцияләр, семинарлар, конкурслар, күргәзмәләр үткәреп, ел саен үткәрелә торган «Без сәламәт яшәү рәвеше өчен» массакүләм профилактика акциясен оештыру | БК МИ, БК ЯЭИ, БК МИ, БК Ф һ СИ | 2017-2020 еллар | Акцияләрдә катнашучылар саны, берәмлек | 43600 | 43750 | 44200 | 45000 | 45000 | Чара оештыру характерына ия |
| Халык арасында тәмәке тарту, алкоголизм һәм наркомания кебек тискәре күренешләрне бетерү буенча шәһәрнең массакүләм мәгълүмат чараларында социаль реклама һәм материаллар урнаштыру | БК МИ, БК ЯЭИ, БК МИ, БК Ф һ СИ, БК ИҮ һ ЭЯКИ, Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | 2017-2020 еллар | Массакүләм мәгълүмат чараларында (радио, телевидение, матбугат, Интернет) урнаштырылган мәгълүмати материаллар саны, берәмлек | 28 | 30 | 35 | 40 | 45 | Чара оештыру характерына ия |
| Шәһәрнең җәмәгать урыннарында спиртлы эчемлекләрне чамадан тыш куллануны булдырмау максатында рейдлар оештыру һәм үткәрү | БК МИ, БК ЯЭИ, БК районнар хакимиятләре | 2017-2020 еллар | Балигъ булмаганнар арасында исерек хәлдә кылынган җинаятьләр саны | 210 | 220 | 250 | 250 | 250 | Чара оештыру характерына ия |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 бурыч. Алкогольле продукцияне чамадан тыш кулланучыларга, алкоголизм белән авыручыларга наркологик медицина ярдәме күрсәтүне оештыруда ярдәм күрсәтү | | | | | | | | | |
| Наркологик ярдәм күрсәтүче, алкогольле патология белән авыручыларны дәвалаучы һәм реабилитацияләүче махсуслаштырылган медицина оешмалары эшен оештыруда ярдәм күрсәтү | БК районнар хакимиятләре | 2017-2020 еллар | Алкогольгә бәйлелеге булган һәм стационарда дәваланган авырулар санында алкогольгә бәйлелеге булган һәм реабилитация узган авыруларның өлеше | 6,7 | 10 | 10 | 10 | 10 | Чара оештыру характерына ия |
| 5 бурыч. Халыкның төрле катлауларын сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләрен формалаштыруга юнәлдерелгән даими физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү | | | | | | | | | |
| Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга юнәлдерелгән массакүләм акцияләр үткәрү | БК МС һ ҖЭИ, БК МИ, БК ЯЭИ, БК Ф һ СИ,<br>БК районнар хакимиятләре | 2017-2020 еллар | Массакүләм акцияләр саны | 32 | 34 | 35 | 36 | 37 | Чара оештыру характерына ия |
| «Спорт – начар гадәтләргә альтернатива» Бөтенроссия акциясенең республика этабында катнашу » | БК МЯЭИ | 2017-2020 еллар | Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми санында акциядә катнашучы укучылар өлеше, процент | 94,6 | 95 | 95,2 | 95,4 | 95,6 | Чара оештыру характерына ия |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова